# Камышлинские известия

ГАЗЕТА МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА КАМЫШЛИНСКИЙ

газета основана в 1931 году

12+

23 ноября 2018 года Пятница №86 (9668)


**25 НОЯБРЯ - ДЕНЬ МАТЕРИ В РОССИИ**

## Поздравляем!

**ДОРОГИЕ ЖЕНЩИНЫ, МАМЫ! СЕРДЕЧНО ПОЗДРАВЛЯЮ ВАС С ОДНИМ ИЗ САМЫХ ТЕПЛЫХ И ДУШЕВНЫХ ПРАЗДНИКОВ - ДНЕМ МАТЕРИ!**



*Этот замечательный праздник посвящен самому важному человеку в жизни каждого из нас. Теплота мамы согревает нас с первой минуты жизни, а незаменимая материнская любовь и вера поддерживают в любом возрасте. Материнство - это большое счастье и огромная ответственность, неустанный труд и самоотверженная забота о своих детях. Именно от матери ребёнок получает первые уроки нравственности, духовности, справедливости и любви к своей Родине.*

*Особых слов признания заслуживают многодетные матери и женщины, ставшие родными приёмным детям. Низкий вам поклон! Безграничная благодарность женщинам старшего поколения - нашим мамам, бабушкам и прабабушкам. Добрые пожелания счастливого материнства тем, кто только готовится стать матерью.*

*Пусть в ваших домах всегда живут радость и уют, будут здоровы родные, а вас окружает искренняя любовь детей, внуков и правнуков. От всей души желаю вам здоровья, счастья, благополучия и больше поводов радоваться за своих детей.*

**Р.К. Багаутдинов.**
**Глава муниципального района Камышлинский, секретарь местного отделения ВПП «Единая Россия»**

**ДОРОГИЕ ЖЕНЩИНЫ! МИЛЫЕ МАМЫ!**



*Примите искренние и сердечные поздравления с замечательным, трогательным, пронизанным особым светом любви и нежности праздником - Днем матери!*

*Этот праздник важен для каждого из нас. Этот день – день глубокого уважения и любви к вам, дорогие мамы, от дочерей и сыновей, признание вашей огромной роли в жизни общества. Именно вам мы обязаны жизнью, семейным уютом и всем лучшим, что у нас есть.*

*Вы радуетесь первым нашим победам и помогаете пережить первые горькие неудачи. И сколько бы лет нам ни было, вы всегда остаетесь для нас молодыми, красивыми и самыми любимыми, а мы для вас - детьми, которым нужна материнская опека и нежность.*

*Искренне желаю вам здоровья, тепла и взаимопонимания в семьях, добра и спокойствия вашим сердцам.*

**Ф.Ф. Шаймарданов.**
**Председатель Собрания представителей муниципального района Камышлинский**

**ДОРОГИЕ ЖИТЕЛЬНИЦЫ КАМЫШЛИНСКОГО РАЙОНА!**



*Сердечно поздравляю вас с одним из самых душевных праздников - Днём матери!*

*Мы многим обязаны самым дорогим нашему сердцу людям - мамам. Этот праздник - замечательная возможность выразить свою благодарность и безграничную признательность за все, что делают для нас наши мамы, за их любовь и понимание.*

*Материнство - это великая ответственность, требующая от женщины огромного терпения и самоотдачи. Быть мамой - большой труд. Кроме выполнения своего священного материнского долга вы самоотверженно трудитесь во всех отраслях экономики и социальной сферы, внося неоценимый вклад в развитие и процветание района и области.*

*Пусть в ваших сердцах царит спокойствие и доброта, а тревог и забот будет как можно меньше. От всей души желаю вам здоровья, счастья, семейного благополучия, взаимопонимания и ответного тепла от своих детей.*

**В.А. Субботин. Депутат Самарской губернской думы, генеральный директор ООО «Газпром трансгаз Самара»**


**Продолжается подписка на газету "Камышлинские известия"**



стоимость подписки на полугодие:
С ДОСТАВКОЙ - 398,82 руб.;
ЛЬГОТНАЯ (ветераны ВОВ, инвалиды) - 337,56 руб.;
БЕЗ ДОСТАВКИ (в редакции) - 95 руб.

**Оформить подписку можно в любом отделении почтовой связи или у почтальонов.**


# СКАЖИ СПАСИБО МАМЕ










*Из поколения в поколение для каждого человека мама – самый главный человек в жизни. В нашем районе очень много женщин, которые достойны добрых слов, которые поистине заслуживают всеобщего уважения за свои поступки. Кто-то отличился мужеством, кто-то - добротой, а кто-то стал самым родным человеком чужому ребёнку. Все они - героини, ярко проявившие себя в воспитании детей.*

*Счастья много не бывает. Так считают многие многодетные матери, чьи сердца переполнены безграничной любовью к детям. Это чувство - чудесное украшение жизни, вечный источник вдохновения, оно делает мир ярким и многоцветным. А родить и воспитать нескольких детей в нашей жизни - настоящий подвиг. Когда же дети вырастут, рядом с ними всегда будут родные, будет большая семья, которой стоит гордиться.*

*Этот праздник - только лишь повод для каждого из нас сказать маме спасибо.*

**ХОРОШАЯ НОВОСТЬ**

# Богатый урожай начинается с хорошей техники

8 НОВЫХ КОМБАЙНОВ ПОПОЛНЯТ ПАРК ЗЕРНОУБОРОЧНОЙ ТЕХНИКИ ООО СХП «РАЗДОЛЬНОЕ»




Илюся Гайнуллина.
Фото автора.

Машинно-тракторный парк в сельском хозяйстве - одна из важнейших составляющих успеха в проведении полевых работ. А такое крепкое растениеводческое предприятие в районе как ООО СХП «Раздольное», входящее в агрохолдинг «Зерно Жизни» группы компаний СИНКО, требует более широкого спектра спецтехники, которая позволяет обрабатывать большие площади и выращивать конкурентоспособную культуру.

НОВАЯ ТЕХНИКА – ЗАЛОГ УСПЕХА

Во вторник днем в хозяйство привезли четыре новых зерноуборочных комбайна Acros 595 Plus от завода «Ростсельмаш». Сейчас новенькие комбайны поставлены на зимнее хранение. Все комбайны закуплены в сборе - с прицепами для жаток. Сегодня парк зерноуборочной техники предприятия насчитывает 8 комбайнов Acros и 7 Вектор.

- Ежегодно компания СИНКО активно инвестирует в покупку сельскохозяйственной техники. Вот и для сезона - 2019 для нашего хозяйства закуплены восемь единиц новой техники, необходимой для уборочных работ. Четыре современных комбайна Acros 595 Plus уже прибыли в хозяйство, планируем до конца этой недели получить еще четыре комбайна такой же модели. Приобретение новой качественной и надежной техники позволит намного сократить сроки проведения уборочных работ зерновых культур и подсолнечника при сезонной нагрузке более 1000 гектаров на один комбайн.

⇨ 4

РАВНЕНИЕ НА ЛУЧШИХ

# Достойно заявили о себе

*Когда успешен педагог, успешны и его ученики. А для детей с ограниченными возможностями здоровья личный пример педагога, его профессиональная активность является особенно значимым.*

Министерство образования и науки Самарской области объявило в 2018 году конкурс профессионального мастерства педагогических работников, связавших свою деятельность с детьми с ограниченными возможностями здоровья. Педагоги школы-интерната имени А.З. Акчурина сумели достойно заявить о себе на весь регион. Успешно пройдя заочный тур, три педагога нашей школы представили свои работы в виде презентации и провели открытые уроки в школах города Самара.

1 ноября состоялась церемония награждения победителей и призеров конкурса. Социальный педагог Юлия Шафигуллина завоевала сердца жюри и стала победителем в номинации «Воспитатель». В номинации «Учитель – предметник» Рамзия Шарафутдинова заняла почетное III место. Воспитатель Гульнара Насырова стала финалисткой этого конкурса.

Коллектив школы гордится вашими успехами, уважаемые мастера коррекционной педагогики, и желает энтузиазма и дальнейшего воплощения интересных замыслов на ниве образования.

**Г.А. Аглиуллина, зам. директора по воспитательной работе.**



*Наши героини умудряются успешно совмещать профессиональную деятельность и роль мамы.*

ТРАДИЦИИ

# ЮИД - это стиль жизни!

*На базе Камышлинской школы прошел традиционный ежегодный районный конкурс-фестиваль юных инспекторов движения среди образовательных организаций района под девизом: "Безопасность на дорогах - гордость! Да здравствует мой регион - Самарская область!".*



Конкурс-фестиваль был организован СП "Созвездие" с участием инспектора по пропаганде БДД отделения ГИБДД МО МВД России "Клявлинский" старшего лейтенанта полиции А.П. Дубникова. И проводился он по двум возрастным группам: учащиеся до шестого класса и учащиеся седьмых-одиннадцатых классов. В первой группе участвовали шесть команд, а во второй - три. Выступление команд было посвящено деятельности юных инспекторов движения в условиях современности и имело агитационную направленность на формирование у участников дорожного движения культуры и навыков безопасного поведения на улицах и дорогах.

С каждым годом уровень подготовки команд возрастает. И в этом году все команды выступили на высоком уровне. Особо хочется похвалить руководителей команд школы села Русский Байтуган за подготовку младшей и старшей групп. Содержательность сценария, зрелищность номеров, яркие костюмы, разнообразный реквизит - всё это поставило перед членами жюри непростую задачу - выбрать лучших из лучших. В итоге все команды получили призовые места.

В младшей группе победителем стала команда "Кадеты" СП "Созвездия" Камышлинской школы, второе место заняли команды школ села Старое Ермаково, Русский Байтуган и "Свежий ветер" школы-интерната им. А.З. Акчурина. Третье место поделили между собой команды Балыклинско и Никиткинской школ.

В старшей группе победителем была признана команда "Продвинутая молодежь" Камышлинской школы, второе место заняла команда школьников села Русский Байтуган, а третье место - ребята Новоусмановской школы.

Команды-победительницы неплохо выступили на зональном этапе конкурса-фестиваля ЮИД в городе Отрадный.

**А.Р. Шайдуллина, методист СП "Созвездие".**

ХОРОШАЯ НОВОСТЬ

# Богатый урожай начинается с хорошей техники

Следует напомнить, что в 2018 году в ООО СХП «Раздольное» поступило 4 единицы новой сельхозтехники: трактор «Беларус-2022», посевной комплекс «Томь-206», опрыскиватель «Туман-2», мульчировщик МН-25 и другое прицепное и навесное оборудование. Совсем скоро ожидается поступление посевного комплекса Amazone, а в начале следующего года - трактора Кировец.

ТЕХНИКУ С ПОЛЯ - НА ХРАНЕНИЕ

Для работников ООО СХП «Раздольное» успешно завершен очередной сельскохозяйственный год. Убраны зерновые культуры и подсолнечник. На календаре ноябрь. Сельхозмашины и агрегаты, освободившиеся от работы в поле, поставлены на зимнее хранение.

- Хранение машин – это комплекс организационно-технологических мер, обеспечивающих защиту машин, их агрегатов, узлов и деталей от коррозии, старения, деформаций и других разрушающих воздействий, - поясняет руководитель хозяйства Фаиль Шаймарданов. - В нашей стране еще никто не отменял стандарт правильного хранения аграрной техники - ГОСТ 7751-71 «Техника, используемая в сельском хозяйстве. Правила хранения».

На сегодня в хозяйстве техника - в полной готовности. Механизаторы вымыли, вычистили доверенную им технику, обмотали полиэтиленовыми мешками колеса и шланги, поставили на зимнее хранение. В парке вместе собраны бороны, культиваторы, сеялки.

С особым уважением отзывается руководитель хозяйства о всех инженерно-технических работниках и механизаторах, которые провели огромную работу в подготовке к длительному зимнему хранению машин.

- Как пример трудового отличия можно назвать каждого человека в нашем коллективе, многие с огромным опытом работы, - с гордостью отзывается о сотрудниках хозяйства Фаиль Фоатович, - В любом производственном вопросе можно положиться на каждого, никто не подведёт.

ЧЕЛОВЕК ДЕЛА

# Пример жизненной стойкости



Ее знают многие в районе. Гульфиря Ахметшина работает старшим инспектором по делам несовершеннолетних в отделении полиции №56. Работе отдаёт душу. Энергичная, идейная, открытая. И очень приятно, когда работаешь и понимаешь, что твой труд не напрасен, когда чувствуешь свою реализованность, как специалиста. И вдвойне приятно, когда твой труд по достоинству оценивает руководство. Благодарственное письмо администрации Камышлинского района, торжественно врученное главой района Р.К. Багаутдиновым на празднике дня сотрудника органов внутренних дел РФ, - своего рода признание, знак того, что ее работу оценили по заслугам.

Счастье матери - это счастье ее ребенка. Однако не всегда получается создать полную семью, на то бывают свои причины, как в случае с Гульфирой Минхайдаровной. Но женщины, которые смогли, которые отважились сделать жизнь своему ребёнку такой же счастливой, как в других семьях, несмотря на жизненные обстоятельства, вдвойне заслуживают уважения за своё мужество. Они - пример жизненной стойкости. Гульфира Ахметшина воспитывает свою дочь Ильмиру такой же позитивной, как она сама, с широкой душой и добрым сердцем.

СЧАСТЬЕ В КОНВЕРТЕ

# С благодарностью - к матери солдата



Ирина Макарова.

***Прекрасным подарком к предстоящему празднику - Дню матери стала благодарность от командования войсковой части, адресованная жительнице села Камышла Гульнур Шайхутдиновой, за воспитание настоящего патриота своей Родины. Сын Гульнур Тагзимовны - Ильназ проходит срочную воинскую службу в Нижегородской области.***

*«Находясь вдалеке от дома, он с честью выполняет Ваш наказ и с достоинством несет высокое звание военнослужащего Вооруженных сил РФ. Вы можете гордиться тем, что ваш сын не испугался трудностей армейской службы, а как настоящий гражданин России с достоинством занял место в строю защитников Отечества. Будем верить, что и в дальнейшем ваш сын останется настоящим гражданином и патриотом своей страны»* - говорится в письме.

# 25 ноябрь - Әниләр көне

Әниләргә мәдхия

## Сагыну гына җанны әрнетә...



*“Минем әле бик бәхетле чагым, яннарымда сөйгән ярым, балаларым”.*

Рәйсә Төхбәтшина.

Фоторәсем гаилә архивыннан алынды.

***Әни! Шушы исемне әйтү белән кеше күңеленә никадәрле җылы хисләр килә, нинди нурлы яктылык сирпелә. Бала чактан, әле әниебезнең муенына сарылып үскәндә үк, без бу исемне чиксез ярату, гамьсез шатлык, ләззәтле куаныч белән әйтәбез. Инде еллар үтеп, үзебез дә олыгаеп килгәндә, (бигрәк тә читтә яшәсәк) бу кадерле исем сагынуга, моң белән сагышка төрелә. Бу олы исем безне гомеребез буе озата килә һәм инде бары тик газиз әниләребезнең хәер-фатихасы белән генә эшләгән эшләребез дә, кылган гамәлләребез дә игелекле, уңышлы була.***

***Әниләрнең изге догалары безне саклый да, яклый да.***

1947 нче елның май аенда, Үзбәкстанда, Китаб шәһәрендә, Шәмсемәгарь һәм Габделхак Шакуровлар гаиләсендә дөньяга аваз сала кыз бала. Ләкин пар канатлы булып үсәргә язмаган була шул кызчыкка. 9 айлык чагында сабый әнисен мәңгегә югалта. Яңа Ярмәк авылыннан булган Габделхак ага туган якларга кайта һәм Камышлыда яшәүче Миннур апага өйләнә. “Үз әниемне фоторәсемнән күреп кенә беләм. Мин үсеп җиткәндә генә әниемнең үги икәнен белдем. Бик яхшы, чиста күңелле кеше иде Миннур әни. Ул мине беркайчан да читкә типмәде. Энем Исхак белән сеңелем Сәриягә дә: “Апагызны тыңлагыз, апагызны олылагыз”, диеп тора иде. Ашсуга оста, пөхтәлек яратучы әниебез янында без дә үрнәк алып үстек”, ди язмам герое.

Тәртипле кыз мәктәптә дә яхшы укый. 1965 нче елны урта мәктәпне тәмамлап таныклык ала да, читтән торып укырмын әле диеп, Кләүле станцасында ике телдә чыгып килүче газетаның татар телендәгесенә - “Ватан байрагы”на корректор булып эшкә урнаша. Татар телен, туган телен камил белү Розаның эшендә дә нык ярдәм итә.

Шушы эш урынында ул үзенең мәхәббәтен, бердәнберен очрата. Сабирҗан Якупов редакциядә шофер булып эшли. Егет белән кыз бер-берсенә бер күрүдә гашыйк булалар. Сабирҗан тәүфыйклы, тәртипле, уңган егет булып үсә. Шулай булмыйни! Сукыр әнисе ялгызы тәрбияләп үстергән бит аны!

1969 нчы елның март аенда Роза белән Сабирҗан бер-берсенә: “Гел бергә, бөтен гомергә”, диеп антлар биреп, чәчләрен чәчкә бәйли. Нурҗинан апа килененең игелекле, уңган, пөхтә икәнен, улын яратканын күңел күзе белән күрә һәм аны үз кызыдай кабул итә. Әлбәттә, Роза апа да әнисен хөрмәт итә, өрмәгән җиргә дә утыртмый. Бер-берсен аңлап, киңәшләшеп 30 ел яши алар.

Роза апа 1991 нче елны “Камышлы хәбәрләре”нә корректор булып күчә. Мин аның белән 1995 нче елны редакциягә эшкә килгәч таныштым. Сабыр, акыллы, итәгатьле хатын икәне йөзенә язылган иде аның.

Ә 50 еллык юбилеена өйләренә баргач аның гаиләсе белән дә танышырга туры килде. Искиткеч матур пар иде алар! Әбекәй дә үз бүлмәсенең түрендә Ак әби булып утыра. Бәхетле гаилә, матур парлар, диеп, сокланып кайткан идем.

Әлбәттә инде алар, бик бәхетле әти-әни дә иделәр: егет солтаны булган Наилне (1970 елгы) һәм сылукай Светлананы (1974) дөньяга китереп, тәрбияләп үстергән алар. Балаларга белем биреп, матур итеп туйларын уздырып, оядан очырган.

Наил-хәрби офицер булып читтә хезмәт итте һәм гаиләле булып, читтә яшәп тә калды. Тормыш иптәше Виктория белән ике онык бүләк итте алар әти-әниләренә: Яна хәзер үзе тормышлы инде, ә Руслан унынчы сыйныф укучысы.

Менә бу шигырь юллары Роза апага улыннан сәлам булып барып ирешсен:

*Уйларымда бары сагыну гына,*
*Сагыну гына җанны әрнетә.*
*Сагыш белән тулы төнем минем,*
*Сагыну белән тулы һәр иртә.*
*Төннәр буе, әнкәй, яңгыр яуса,*
*Бел син аның яңгыр түгелен.*
*Тәрәз кага дәрвиш-яңгыр булып,*
*Хәлең сорап минем күңелем.*

Светлана үзебезнең авылга килен булып төште. Бик матур, пар килгән Рәис ага һәм Нәкыя апа гаиләсендә туып, акыллы егет булып үскән Рамиль Мөхәммәтҗанов яры ул. Тормышлары мул, җайлы аларның. Кызлары Динара да алар үрнәгендә бик акыллы, чибәр булып үсеп җитте. Бердәнберләрен читкә дә җибәрәселәре килми әти-әнинең. Әлегә кызлары яннарында, урман хуҗалыгында финансист булып эшли. Аңа да үз тиңен табып, бәхетле гомер кичерергә язсын. Амин.

Мул тормышның игелеген күреп, балаларының, оныкларының уңышларына, тормышларына куанып яшәргә дә, яшәргә иде дә бит! Гел без уйлаганча гына түгел шул ул тормыш дигәнең. Роза апаның да аяз күген кинәт болыт каплады. Көтмәгәндә-уйламаганда аның Сабирҗаны мәңгелеккә китеп барды. 48 ел буена Сабирҗанының канаты астында сөеп-сөелеп яшәгән Роза апа боегып калды, гүя аның канатлары каерылды, яшәвенең мәгънәсе югалды. Аның җаны сыкрый. Камышлы белән Кләүле арасында бәргәләнә ул. Балалары: “Әни, бездә генә тор инде”, дисәләр дә, бер-ике кич куна да, тагын үз өенә кайтып китә, гүя аны анда Сабирҗаны көтә.

Роза апа сирәк кенә булса да, безнең хәлләрне дә белеп чыга. Әмма, элеккеге бәхетле, пар канатлы, гел елмаеп торучы Роза апаның әсәре дә калмаган. Минем аның кулларыннан аласым, күзләренә карап “Хәлләрең ничек, җаным?”- диясем, авыр югалтулар миңа таныш, хәсрәтеңне миңа сөйлә син дип, әйтәсем килә.

*Гомер юлдашымны югалттым дип,*
*Утлар йотып, хәсрәт чигәсең.*
*Авыр югалтулар миңа таныш,*
*Хәсрәтеңне миңа сөйлә син.*
*Бу якты дөньядан китсә дә ул,*
*Ятим итеп гомер юлдашын,*
*Киткәннәрне сагыныр өчен яшә,*
*Шулдыр синең хәзер язмышың.*
*Сагыну үзе яшәү, сагын аны,*
*Хыялыңда яшәт төргезеп.*
*Син булмасаң кем соң аны җирдә*
*Сагыныр иде шулай өзелеп?..*
*Ай батканда күктә йолдыз кала,*
*Җир өстенә нурын чәчәргә.*
*Без калабыз, ахры, үткәннәрне*
*Гомер буе сагынып яшәргә...*



***Менә 20 ел инде ноябрь аеның соңгы якшәмбесе Әниләр көне итеп билгеләп үтелә.***

*Җир йөзендә әнидән дә күркәм, әнидән дә сөйкемле зат юк ул. Һәркайсыбызның әнисе үзенә кадерле. Алар безне тапкан, баккан. Әз генә чирләсәк тә көенгән, безнең тәпи йөреп китүебезне күреп, беренче авазларыбызны, сүзләребезне ишетеп сөенгән. Әниләребез безне күз карасыдай саклап, карап үстергән, укыткан, олы тормыш юлына озаткан. Әниләрнең изге догалары, хәер-фатихасы безне гомер буе саклап бара. Без алар алдында мәңге бурычлы.*

*Әниләргә багышлап күпме шигырьләр, җырлар, романнар язылган. “Ана - бөек исем, нәрсә җитә ана булуга? Хатын-кызның бөтен матурлыгы, бөтен күрке ана булуда”-, - дигән бит шагыйрь Һади Такташ та. Нинди матур шигырь юллары! “Мәхәббәте һичбер киртәләрне белми торган, күкрәк сөте белән бөтен дөньяга хәят биргән Ананы олылыйк. Кешедә булган гүзәллек кояш нурыннан һәм ана сөтеннән килә, менә шулар безнең йөрәкләрне яшәүгә мәхәббәт белән сугаралар! Мәхәббәтсез бәхет юк, хатын-кызсыз мәхәббәт юк, анасыз шагыйрь дә, батыр да юк”,-дигән “Ана” романы авторы, рус язучысы Максим Горький.*

*Әниләр бердәнбер бит ул һәм алар мәңгелек тә түгел. Шуңа күрә аларның кадерен исән чакта белик, аларны ялгызлыктан саклыйк. Әгәр дә без әниләрне кадерләп яшәсәк, үзебез дә балаларның кадер-хөрмәтен күрербез. Бәйрәм белән, кадерлеләребез!*

## Бәйрәм күчтәнәче

***Матур теләкләр, моңлы җырлар, эчтәлекле шигырь юллары кебек тә кыйммәтле күчтәнәч бармы икән ул?! Газиз, кадерле кешеләребез! Сезгә бәйрәм күчтәнәче итеп моңлы-җырлы шагыйрә Шәмсия Җиһангированың ике шигырен бүләк итәбез.***

### Әнкәм назы

*Бишекләргә салгансыңдыр сөеп,*
*Назлап үпкәнсеңдер битемнән.*
*Ул назны мин инде хәтерләмим,*
*Чоңгылына еллар яшергән.*
*Әллә нишләп сыкрап куя күңел,*
*Син, әнием, искә төшкәндә.*
*Бишекләрдә бер тибрәлер идем,*
*Белмәгәндә niләр эшләргә.*
*Исемә төшер: нинди иде ул наз-*
*Әнкәм назы, әнкәм җылысы?*
*Инде үзем әни булсам да мин,*
*Синең нәни кызың булыймчы?!*
*Кагыл әле минем чәчләремә,*
*Назлап салчы, әнием, бишеккә.*
*Синең назны тойсам, башкасына*
*Түзәрмен, бирешмәм ничек тә...*

### Сагынам сине

*Яшел чирәм өсләрендә ап-ак томаннар ята,*
*Иртәнге чыкны уятып, әкрен генә таң ата.*
*Кошлар уята баласын, сайрашырга пар булып,*
*Әнием, бәгърем, сагынам сине бер күрергә зар булып.*
*Күбәләкләр гөлдән- гөлгә кунаклап оча башлый.*
*Минем генә йөрәккәем өзгәләнә, ямь тапмый.*
*Кошлар уята баласын, сайрашырга пар булып,*
*Әнием, бәгърем, сагынам сине бер күрергә зар булып.*
*Үз-үземне юатам мин шундый моңсу чакларда,*
*Илтер диеп юллар мине син яшәгән якларга.*
*Кошлар уята баласын, сайрашырга пар булып,*
*Әнием, бәгърем, сагынам сине бер күрергә зар булып.*

### Әнкәм гөле

*Туган көнемә турылап,*
*Чәчәк атты гөлең.*
*Ник соң, әнкәй, өйрәтмәдең*
*Миңа гөлләр телен?*
*Кышын чәчәк аткан гөлең*
*Үзең кебек түзем.*
*Балачактан кайтаваз күк*
*Ишетелә сүзең.*
*Балам, гөлләр телсез алар,*
*Җанын тоеп яшә.*
*Мәңгелектән сабыр гына*
*Миңа әнкәм дәшә.*
*Әнкәм бүләк иткән гөлгә*
*Тама әче яшем.*
*Өйрәтергә гөлләр телен,*
*Юк кадерле кешем.*
*Ак кышлардан курыкмыйча*
*Чәчәк атты гөлем.*
*Нәкъ синеңчә тоям, әнкәй,*
*Телсез гөлләр телен.*

**Фирдәүсә Кәримова.**

### Әниемә

**Әнием Гөлчирә Әхмәдуллинага багышлыйм.**

*Кайтабыз да нидер җитми кебек*
*Сагындыра бигрәк әтием,*
*Бәйрәм белән котлап, шигырь яздым сиңа*
*Кабул итеп алчы, әнием.*
*Нигә икән күгәрченнәр*
*Тал башына оя коралмый,*
*Кыз бала ничек сагынса да*
*Туган нигезендә калалмый.*
*Сагынасыңдыр, беләм әнием,*
*Мин бит синең бердәнбер кызың,*
*Кайтабыз да, озакка калалмыйбыз*
*Тагы каласың шул ялгызың.*
*Оныкларының да туен күрәлмичә*
*Иртә китте бигрәк әтием,*
*Бик күп еллар әле, насыйп булсын сиңа*
*Каршы алырга безне, әнием.*
*Җиңгелләрдән булмагандыр, әни*
*Без үскәндә тормыш юллары,*
*Бирешмичә каршы искән җилгә*
*Калды тезелеп гомерең еллары.*
*Уянам да сызылып таң атканда*
*Үрәм икеләтә толымны,*
*Биреп миңа хәер-фатихаңны*
*Яктырт әнием, барыр юлымны.*

**Флюра Баһаутдинова.**

*Материалларны басмага Рәйсә Төхбәтшина әзерләде.*

# Котлыйбыз!

**Камышлы авылы Роза Мөхәсин кызы Гариповага-80 яшь**

Кадерле әниебез, яраткан әбиебез! Сине ихлас күңелдән юбилееӊ белән тәбриклибез.

*Менә, әни, туган көнеӊ житте,*
*Туган көн ул-бәйрәм тантана.*
*Бу көн безне туган йортка жыя,*
*Шуңа, әни, күңел шатлана.*
*Туган көнеӊ синеӊ котлы булсын,*
*Рәхмәтебезнеӊ сиңа олысы.*
*Гомер буе сине саклап йөртсен,*
*Аллаһының хәер-догасы.*

**Иң изге теләкләр белән кызың Венера, киявеӊ Нурулла, оныкларың Эдуард, Эльмира гаиләләре белән-Лениногорск һәм Чиләбе шәһәрләреннән.**

***

**Роза Мөхәсин кызы Гариповага**

Газиз әниебез, сөйкемле әбиебез! Сине саф күңелдән юбилееӊ белән тәбриклибез.

*Рәхмәт, әни, гомер бирүеңә,*
*Төн йокыларыңны бүлүеңә.*
*Безгә нык канатлар куюыңа,*
*Ышанычлы терәк булуыңа.*
*Әни бит ул өйнеӊ яме,*
*Ә тормышта олы бер терәк.*
*Сәламәт бул, озак яшә,*
*Син бит, әни, безгә гел кирәк.*

**Улыӊ Илдар, килениӊ Руфия, оныкларың Алмаз, Альберт, Гөлназ, Ильясик.**

***

**Роза Мөхәсин кызы Гариповага**

Кадерле әниебез, яраткан әбиебез! Без сине юбилееӊ белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Олы җаныӊ, сабыр холыкыӊ, киң күңелле, безгә һәрвакыт төпле киңәшләреӊ биреп яшәүче кадерле кешебезгә, нык сәламәтлек, озын гомер, шатлык, җан тынычлыгы, бәхет телибез.

*Без бәхетле, әни, син булганга,*
*Балам, диеп өзелеп торганга.*
*Рәхмәт әйтеп, баш иябез сиңа,*
*Бүген 80 яшеӊ тулганда.*
*Эш-гамәлеӊ синеӊ маяк кебек,*
*Киңәш сүзеӊ булды таманга.*
*Мәрхәмәтле үзеӊ, сокландыра,*
*Кулларыңнан гөлләр тамганда.*

**Җылы теләкләр белән улың Айдар, килениӊ Гөлчәчәк, оныкларың Айнур, Айгөл, Раил, онықчыгың Артур.**

***

**Рәис Газиз улы Вәлиевка-80 яшь**

Хөрмәтле туганыбыз! Сине олы йөрәктән юбилееӊ белән тәбриклибез.

*Изге теләк, назлы сүздән башка,*
*Табып булмый затлы бүләкне.*
*Безнеӊ өчен бик тә кадерле син,*
*Бик тә якын, бик тә кирәкле.*
*Сәламәт бул, озак еллар яшә,*
*Сызламасын аяк-кулларың.*
*Бүгенгедәй бергәләшеп үтик,*
*Киләчәктә гомер юлларын.*

**Изге теләкләр белән Алсу һәм Әгъдәс.**

**Рәис Газиз улы Вәлиевка**

Кадерле, якын кешебез! Сине кайнар йөрәктән юбилееӊ белән котлыйбыз.

*Дөньядагы һәрбер яхшылыктан,*
*Өлеш чыксын сиңа мул гына.*
*Без телибез сиңа ак бәхетләр,*
*Шатлыкларга илткән юл гына.*
*Бәйрәмеңнеӊ матур хатирәсе,*
*Күңелеңдә калсын уелып.*
*Тәбриклибез сине чын күңелдән,*
*Барыбыз да бергә җыелып.*

**Равил, Тәнзилә һәм балалар-Чулпан поселогыннан.**

***

**Гөлшат Гакыйл кызы Дәрҗемановага-50 яшь**

Хөрмәтле кешебез! Сине саф күңелдән юбилееӊ белән котлыйбыз.

*Ак чәчәккә күмгән сыман язмыш,*
*Кызганмасын сиңа шатлыкны.*
*Кояш нуры кебек балкып торган,*
*Рәхәт тормыш, матур киләчәкне.*
*Юбилееӊ белән тәбриклибез,*
*Сәламәтлек теләп иң элек.*
*Һәрбер көнеӊ үтсен шатлык белән,*
*Бәхет-хөрмәтләргә төренеп.*

**Сания, Миңнәхсән һәм аларның балалары гаиләләре белән.**

***

**Чулпан поселогы Гакиф Газый улы Хуҗиевка-60 яшь**

Хөрмәтле тормыш иптәшем, кадерле әтиебез, бабабыз! Сине ихлас күңелдән юбилееӊ белән котлыйбыз.

*Бүген синеӊ юбилееӊ,*
*Ниләр телик синеӊ хөрмәткә.*
*Кыска итеп, җыйнап кына әйтсәк,*
*Син лаеклы кеше чын рәхмәткә.*
*Сәламәтлек синеӊ дустың булсын,*
*Сызламасын аяк-кулларың.*
*Киң һәм якты булсын барыр юлың,*
*Синеӊ кебек булсын дусларың.*

**Тормыш иптәшең, балаларың Лилия һәм Галия гаиләсе белән.**

***

**Гакиф Газый улы Хуҗиевка**

Кадерле әтиебез, яраткан бабабыз! Сине олы йөрәктән истәлекле бәйрәмең белән тәбриклибез.

*Рәхмәт, әти, син булганга,*
*Тормышыбыз күгендә.*
*Терәк булдың син һәрвакыт,*
*Кирәкле син бүген дә.*
*Олы синеӊ биргән киңәшләреӊ,*
*Туры синеӊ әйткән сүзләреӊ.*
*Шатлык, сөенечтән генә торсын,*
*Син үтүче гомер юлларың.*

**Кызларың Алия, Алисә, киявеӊ Фаил, оныкларың Арианна, Амина, Марсель.**

***

**Гакиф Газый улы Хуҗиевка**

Хөрмәтле, кадерле кешебез! Сине чын күңелдән юбилееӊ белән котлыйбыз.

*Без бик шатбыз, мондый күркәм кеше,*
*Безнеӊ өчен якын, кадерле.*
*Йөз яшькәчә аңа гомер телик,*
*Бүләк итик кадер-хөрмәтне.*
*Яшеӊ арткан саен шатлыгың артсын,*
*Җан юлдашың булсын исәнлек.*
*Кылган изгелегеӊ, гамәл кылган кебек,*
*Ахирәткә кадәр җитәрлек.*

**Равил, Тәнзилә һәм балалар.**

**Нургали Рәхмәтулла улы Сафинга-60 яшь**

Хөрмәтле тормыш иптәшем, кадерле әтиебез, яраткан бабам! Сине чын күңелдән юбилееӊ белән тәбриклибез.

*Котлы булсын юбилееӊ,*
*Туган көнеӊ-гомер бәйрәмеӊ.*
*Кабул ит син бездән зур бүләкне,*
*Изге теләкләрнеӊ бәйләмен.*

**Тормыш иптәшеӊ, балаларың, оныгың Самира.**

***

**Нургали Рәхмәтулла улы Сафинга**

Кадерле абыебыз! Сине кайнар йөрәктән юбилееӊ белән котлыйбыз.

*Туган көнеӊ кебек ямьле булсын,*
*Яшәр елларыңның агышы.*
*Дәрт-дәрманлы булсын яхшылыңның,*
*Яшәр өчен канат кагышы.*

**Сеңелеӊ Лилия, киявеӊ Рамил һәм балалар.**

***

**Нургали Рәхмәтулла улы Сафинга**

Яраткан, якын кешебез! Сине юбилееӊ белән ихлас күңелдән тәбриклибез.

*Алгы көнеӊ бәхет белән үтсен,*
*Йөзләреӊә нурлар сибелсен.*
*Аяз көннеӊ алсу таңы сиңа,*
*Гомерлеккә шатлык китерсен.*

**Апаң Тәслия, җизнәң Ваня һәм балалар.**

***

**Нургали Рәхмәтулла улы Сафинга**

Хөрмәтле гаилә дустыбыз! Сине саф күңелдән юбилееӊ белән котлыйбыз.

*Юбилееӊ котлы булсын,*
*Гомер юлың озын булсын.*
*Балаларың, туганнарың белән,*
*Өй түрләреӊ тулып торсын.*
*Җан рәхәте бирсен Ходай,*
*Тән сихәте бирсен гомергә.*
*Насыйп булсын озак еллар,*
*Бергә-бергә җирдә яшәргә.*

**Гаилә дусларың Гамил, Минзилә, Ранис, Ралия.**

***

**Нургали Рәхмәтулла улы Сафинга**

Кадерле, сөекле туганыбыз! Сине туган көнеӊ-юбилееӊ белән ихлас күңелдән тәбриклибез.

*Якыныбыз, барыр юлларыңда,*
*Бәхет, саулык булсын юлдашың.*
*Туганнарга булган хисләреңә,*
*Тузан бөртеге дә кунмасын.*
*Кабул ит син котлау сүзен,*
*Шушы булсын олы бүләкләр.*
*Тормышыңны яктыртсыннар,*
*Безнеӊ әйткән изге теләкләр.*

**Наилә, Фәрит-Яңа Усман авылыннан.**

# Поздравляем!

**Районный совет ветеранов (пенсионеров) войны и труда, общество инвалидов и первичная общественная организация ветеранов и инвалидов сельского поселения Камышла горячо поздравляют ветеранов труда Валиева Раиса Газизовича, Камалтдинова Рината Нигматулловича, Хайруллину Альфию Мебиновну и Гарипову Розу Мухасыновну с 80-летием.**

Уважаемые ветераны!

*Сегодня мы сердечно поздравляем,*
*От всей души здоровья, светлых дней.*
*Большого счастья, радости желаем*
*В торжественный и славный юбилей.*

***

**Первичная общественная организация ветеранов и инвалидов сельского поселения Камышла от всей души поздравляет председателя районного общества инвалидов З.М.Дерзиманову с 60-летием.**

Уважаемая Зульфия Мардугалимовна!

*Успехов и в семье благополучья,*
*Здоровья и всегда погожих дней.*
*Ну, словом, пожеланий самых лучших,*
*Вам в 60, в прекрасный юбилей.*

***

**Коллектив детского сада «Улыбка» райцентра Камышла от всего сердца поздравляет бывшего сотрудника Т.Г.Гибадулина с 60-летием.**

Уважаемый Талгат Гайфиевич!

*В этот день вспоминать приятно*
*Счастливые и радостные дни.*
*Еще приятней-снова строить планы,*
*Пусть непременно сбудутся они.*
*Пускай здоровье крепкое поможет*
*Все замыслы легко осуществить.*
*И рядом будут близкие, родные,*
*Чтоб с ними эту радость разделить.*


**ПРОДАЕТСЯ:**

- колотые дрова (береза). Самовывоз. Тел: 8-987-152-19-86.

***

- газовая плита «Века», шкаф-купе все в отличном состоянии. Тел: 8-929-703-58-99.

***

- а/м ВАЗ-21111, цвет серебристый, на ходу, в удовлетворительном состоянии, цена 25 тыс.рублей. Тел: 8-937-642-51-56.

***

- дом (110 кв.м) в с.Камышла по ул. М.Джалиля, 4. Во дворе имеется гараж, баня, сарай, огород с фруктовыми деревьями, зем.участок 10 соток. Тел: 8-925-799-33-83.

***

- 2-х этажный дом (150 кв.м) с зем. участком 25 соток под ИЖС Похвистневский район, пос.Сукаевка, по ул.Главная. 2016 год постройки из теплого керамзитобетонного блока. Кровля, пласт.окна, черновая отделка. Проведены вода, электричество, газовая труба, в 3м. от дома своя канализация. На участке гараж на 2 автомашины, баня, все строения на армированном фундаменте. Плодоносящие деревья 50 насаждений. Покупателю мотоблок, газонокосилка, сопутствующий инвентарь и дизайн проект в подарок. Цена 2 млн.500 тыс.рублей. Тел: 8-906-344-70-77 (Елена).

**ЗАКУПАЕМ** говядину и вынужденный забой. Тел: 8-927-266-22-20.

**СДАЕТСЯ** 2-х комнатная квартира в с.Камышла. Тел: 8-937-658-24-89.

**КРОВЛЯ** региональная сеть 3 дня
**ПРОФЛИСТ М/ЧЕРЕПИЦА САЙДИНГ**
**8 937 074-36-36**
Выезд замерщика БЕСПЛАТНО!

**Автострахование.**
Тел: 8-917-946-11-11.

Срочная помощь в оформлении
**КРЕДИТА**
Решение за один день
С любой кредитной историей
С минимальным пакетом документов
**8-967-922-25-20**
Обращайтесь к нам и экономьте!
*Не является публичной офертой ООО «Финансово Правовой Центр» не является Банком/Банковской кредитной организацией, оказывает консультативные услуги, ОГРН 1170280032581

**УСТАНОВКА АНТЕНН**
ПОДКЛЮЧЕНИЕ ТРИКОЛОР, ТЕЛЕКАРТА, ЦИФРОВОЕ ТВ. Обмен приемников. Выезд по району. Рассрочка. Услуга электрика.
Тел: 8-927-654-29-88.

**БУРЕНИЕ СКВАЖИН НА ВОДУ**
Тел: 8-927-748-20-05.

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА ОТ ПРОИЗВОДИТЕЛЯ!**
KBE, EXPROF, PROWIN. Высокое качество. Срок изготовления от 2-х дней. Ремонт окон. **ЖАЛЮЗИ, РОЛСТАВНИ.** НИЗКИЕ ЦЕНЫ. Мы умеем делать хорошие окна. Тел: 8-937-203-74-92, 8-927-755-63-91. Реклама. ИНН 635785867777


Районный совет ветеранов (пенсионеров) войны и труда, общество инвалидов и первичная общественная организация ветеранов и инвалидов сельского поселения Камышла искренне скорбят по поводу смерти ветерана труда

**МУХГАЛИМОВОЙ Халисы Зайнулловны**

и выражают глубокое соболезнование семье, родным и близким покойной.


Адрес редакции и издателя: 446970 Самарская область Камышлинский район с. Камышла ул. Победы, 37 А e-mail: miznur@mail.ru www.kamizvestiya.ru

12+

Телефоны: Руководитель: 3-31-47, ответственный секретарь, корреспонденты, верстка, рекламный отдел: 3-30-61.

За содержание рекламы ответственность несет рекламодатель

Руководитель центра и главный редактор Р.Т.БАДРЕТДИНОВ.
Газета выходит по вторникам и пятницам.
*Объем - 1 печатный лист.*
Отпечатана в МУП "Сергиевское полиграфическое предприятие". 446540 Самарская область, с.Сергиевск, ул.Ленина, 14. Заказ №1251

Номер подписан в печать 22.11.2018г. фактически в 12.00 по графику в 12.00

Ответственный секретарь: И.ГАЙНУЛЛИНА
Верстка: Р.ПОЛУКАРОВ.
*Подписной индекс 52436*
*Цена свободная. Тираж - 1300 экз.*

Редакция может не разделять точку зрения автора. Присланные материалы могут подвергаться редакционной правке. Редакция не несет ответственности за содержание рекламных материалов, их политическую направленность и правдивость. Письма, рукописи, иллюстрации не рецензируются и не возвращаются.

Учредители: Администрация муниципального района Камышлинский Самарской области. Газета "Камышлинские известия" зарегистрирована в Управлении Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Регистрационный номер ПИ № ТУ 63-00744 от 02 декабря 2014 года.